**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Карадуган авылында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2025 ел 20 октябрь № 2

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлегенең Карадуган авылыда халык җыены турында карар бирә:

1. 2026 елда Балтач районы Карадуган авыл җирлеге Карадуган авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр бәлигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) урамнарны яктырту җайланмасы кую;
2) тротуарларны төзү, төзекләндерү;
3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр).

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: Ш. В. Низамиев